| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 2 октябре** **№ 10**

**Иске Иштирәк авыл җирлеге Бәкер авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, Иске Иштирәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар КАРАР БИРДЕ:

1. 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге Бәкер авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. «2019 елда Иске Иштирәк авыл җирлеге Бәкер авылы чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән һәр гражданнан 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

- җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә бирелгән вәкаләтләр нигезендә суүткәргеч мөлкәтен карап тоту;
- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
-җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү;

« Әйе Юк».

3. Әлеге карарны Иске Иштирәк авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының

рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Иштирәк авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы Н.Ә. Мәҗитов